**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында гражданнар җыены карары**

12.11.2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Килдураз авыл җирлегенең Казма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт территориясен төзекләндерү, (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү));

-Казма авылында ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (агач төпләрен тамырдан йолкып алу һәм тигезләү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Килдураз авыл җирлеге башлыгы _________ З.З.Әхәтов

Халык җыены секретаре _________ Л.И.Шафигуллина